ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 февраль, 2016 ел № 6/6

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2014 елның 22 октябрендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 311-ФЗ санлы федераль закон, 2015 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 406-ФЗ санлы Федераль закон, 2016 елның 15 февралендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 23-ФЗ санлы федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6, 2015 елның 22 октябрендәгеп 2/14 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 маддәдә:

- 8 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 4.2 пунктын өстәргә:

«4.2.) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан мондый методикага гомуми таләпләр нигезендә бюджетка керемнәр керүне фаразлау методикасын раслый;»;

- 9 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пунктын өстәргә:

«6.1. бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерүгә өметсез дип тану турында карар кабул итә;»;

- 10 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 4.2 пунктын өстәргә:

«4.2) бюджет ассигнованияләренең нигезләнүен төзи.»;

- 10 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пунктын өстәргә:

«7) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан мондый методикага гомуми таләпләр нигезендә бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне фаразлау методикасын раслый.»;

2) 4.1 маддәсендә:

- 1 өлешнең 1 пунктында «тарафыннан» сүзеннән соң «Россия Федерациясе бюджет законнары, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче башка норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

- 2 өлештә «тарафыннан» сүзеннән соң «Россия Федерациясе бюджет законнары, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче башка норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

- 3 өлештә «тарафыннан» сүзеннән соң «Россия Федерациясе бюджет законнары, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче башка норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

3) 5 маддәгә түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пунктын өстәргә:

«6.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә агымдагы финанс елына һәм планнар чорына бюджет турында законның (карарның) нигезләмәләре үз көчен югалта, дип таныган очракта, казна учреждениесе планнар чорында түләнергә тиешле электән төзелгән килешүләрне өзү турында карарны, әлеге килешүләргә аларның планнар чорында үтәлеше шартларын билгеләгән өстәмә килешүләр төзелгән шартта, кабул итмәскә хокуклы.»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 7.1 маддәсен өстәргә:

«7.1. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм аны юкка чыгару (торгызу) турында карар кабул итү

1. Билгеләнгән срокта шәһәр бюджетына түләнмәгән түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч) түбәндәге очракларда түләтүгә өметсез дип таныла:

1) физик затның – шәһәр бюджетына түләүләр түләүченең үлеме яисә Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә аны үлгән дип игълан итү;

2) шәхси эшмәкәрне – шәһәр бюджетына түләүләр түләүчене 2002 елның 26 октябрендәге «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, бурычлының милеге җитәрлек булмау сәбәпле, шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычлар өлешендә банкрот дип тану;

3) оешманы – шәһәр бюджетына түләүләр түләүчене, оешманың милеге җитәрлек булмау һәм (яки) күрсәтелгән оешманың оештыручылары (катнашучылары) тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә аларны түләргә мөмкинлеге булмау сәбәпле, шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычлар өлешендә ликвидацияләү

4) суд тарафыннан акт кабул ителү, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы, бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы үтү белән бәйле рәвештә, бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза бирүнең югалтылган срогын торгызудан баш тарту турында суд тарафыннан билгеләмә чыгару;

5) суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма эшне тәмамлау турында һәм 2007 елның 2 октябрендәге «Башкару хезмәте турында» 229-ФЗ санлы Федераль законның 46 маддәсе 1 өлеше 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләрдә башкарма эшне кайтару турында карар чыгару, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурыч барлыкка килү көненнән биш елдан артык вакыт узган түбәндәге очракларда:

- бурычның күләме, банкротлык турында эш кузгату өчен, бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнары белән бурычлыга билгеләнгән таләпләр күләменнән артык түгел;

- суд тарафыннан шәһәр бюджетына түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза кире кайтарылган яки, банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын түләү өчен җитәрлек средстволарның булмавы белән бәйле рәвештә, банкротлык турында эш кузгату туктатылган.

2. Әлеге маддәнең 1 пункты белән каралган очраклардан тыш, билгеләнгән срокта түләнмәгән административ штрафлар, административ җәза бирү билгеләнү турында карарның Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында кодексы белән билгеләнгән үтәү вакыты узу очрагында, әлеге срокны туктатып тору яки озайту өчен нигезләр булмаганда, түләтүгә өметсез дип танызла.

3. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар бюджет керемнәре администраторы тарафынан әлеге маддәнең 1 һәм 2 пунктларында каралган хәлләрне раслаучы документлар нигезендә кабул ителә.

4. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарны кабул итү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә бюджет керемнәренең баш администраторы тарафыннан билгеләнә.

5. Шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны бюджет (бухгалтер) хисабында юкка чыгару (торгызу) бюджет керемнәренең администраторы тарафыннан шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге маддәнең нигезләмәләре салымнар һәм җыемнар турында законнар, Россия Федерациясенең иминият түләүләре турында законнары, Таможня берлегенең таможня законнары һәм Россия Федерациясенең таможня эше турында законнары белән билгеләнгән түләүләргә кагылмый.»;

5) 8 маддәдә:

- түбәндәге эчтәлектәге 6.1 маддәсен өстәргә:

«6.1. Әлеге маддәнең 6, 7 өлешләре нигезендә билгеләнүче муниципаль йөкләмәне формалаштыру һәм муниципаль йөкләмәне үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе шул исәптән түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

1) муниципаль йөкләмәне формалаштыру, үзгәртү, раслау кагыйдәләрен һәм срокларын, аны үтәү турында хисапны;

2) муниципаль йөкләмәне үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләмен билгеләү кагыйдәләрен һәм срокларын, түбәндәгеләрне кертеп:

- дәүләти (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнарның төп нормативлары һәм аларга төзәтмә коэффициентлар нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм шулай ук эшләрне башкаруга норматив чыгымнары исәпләү һәм раслау;

- муниципаль йөкләмәне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр күчерү күләме һәм сроклары;

- ирешелмәгән муниципаль йөкләмә күрсәткечләренә туры килгән күләмдә субсидияләрне кире кайтару;

3) муниципаль учреждение тарафыннан муниципаль йөкләмәне үтәүне Башкарма комитет тарафыннан контрольдә тотуны гамәлгә ашыру кагыйдәләре.»;

- 12 өлешнең икенче абзацында «7 пунктта» сүзләрен «6 һәм 7 пунктта» сүзләренә алыштырыга;

- 12 өлешнең унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге өлештә күрсәтелгән субсидияләр шәһәр бюджетыннан муниципаль-хосусый партнерлык турында, концессион килешүләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән муниципаль-хосусый партнерлык килешүләрендә, концессион килешүләрдә каралган шартлар һәм сроклар нигезендә бирелергә мөмкин.»;

- 12 өлешнең унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль-хосусый партнерлык килешүләрен, концессион килешүләрне расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артыграк вакытка төзү, Башкарма комитет карары белән каралган очракларда, Башкарма комитет карары белән билгеләгән тәртиптә башкарыла.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 12.1 пунктын өстәргә:

«12.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе белән каралган субсидияләрне алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта, тиешле средстволар Шәһәр Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә шәһәр бюджетына кире кайтарылырга тиеш.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 12.2 пунктын өстәргә:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе белән каралган субсидияләрне әлеге маддәнең 12 пункты беренче абзацында күрсәтелгән юридик затларга биргәндә, аларны бирүнең товарлар җитештерү (сатып алу), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында килешүләргә кертелгән мәҗбүри шарты булып, алынган средстволар хисабына чит ил валютасын сатып алу тыелу тора, югары технологияле чит илдән кертелгән җиһаз, чимал һәм комплектлаштыручы эшләнмәләрне сатып алганда, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырылучы операцияләрдән, шулай ук күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән әлеге средстволарны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш.»;

- 14 өлештә:

өченче абзацта «субсидияләр бирү турында килешүләргә кертелгән

мәҗбури шарты булып» сүзләрен «субсидияләр бирү турында килешүләргә кертелгән мәҗбури шартлары булып» сүзләренә алыштырыга, «товарлар җитештерү (сатып алу), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында килешүләргә кертелгән мәҗбури шарты булып, алынган средстволар хисабына чит ил валютасын сатып алу тыелу тора, югары технологияле чит илдән кертелгән җиһаз, чимал һәм комплектлаштыручы эшләнмәләрне сатып алганда, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырылучы операцияләрдән, шулай ук муниципаль учреждение булмаган коммерциясез оешмаларга субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән әлеге средстволарны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзацны өстәргә:

Бюджет һәм автоном учреждениеләрнең әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән субсидияләр хисабына түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында килешүләренә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә субсидияләр бирүче бюджет средстволарын алучыга билгеләнгән тәртиптә электән җиткерелгән субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәлре лимиты кимегән очракта, яклар килешүе буенча товарлар, эшләр, хезмәтләрнең күләмен һәм (яки) түләү срогын үзгәртү шарты кертелә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә агымдагы финанс елына һәм планнар чорына бюджет турында законның (карарның) нигезләмәләре үз көчен югалта, дип таныган очракта, казна учреждениесе планнар чорында түләнергә тиешле электән төзелгән килешүләрне өзү турында карарны, әлеге килешүләргә аларның планнар чорында үтәлеше шартларын билгеләгән өстәмә килешүләр төзелгән шартта, кабул итмәскә хокуклы.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 15.1 өлешен өстәргә:

«15.1. Шәһәр бюджеты үтәлеше барышында муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен хәзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгән муниципаль милекнең капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү һәм капиталь төзелеш объектлары мөнәсәбәтендә муниципаль милеккә күчемсез милек объетларын яисә муниципаль милекнең күчемсез милек объектларын сатып алу рөхсәт ителми, әлеге өлешнең икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш.

Шәһәр бюджеты үтәлеше барышында, РФ Бюджет кодексының 79 маддәсендә каралган бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганганда, муниципаль заказчик булып торган казна учреждениесенең тибын билгеләнгән тәртиптә бюджет яки автоном учреждениегә үзгәрткән яисә аның оештыру-хокукый формасын муниципаль унитар предприятиегә үзгәрткән очракта, казна учреждениесе белән электән төзелгән муниципаль контрактларга килешү якларын алыштыру өлешендә (казна учреждениесен – бюджет яки автоном учреждениегә, муниципаль унитар предприятиегә) һәм килешү төрендә (муниципаль контрактны – бюджет

яки автоном учреждениенең, муниципаль унитар предприятиенең гражданлык-хокукый килешүенә) үзгәреш кертеп, күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен хәзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарга тиешле үзгәрешләр керткәннән соң, әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән муниципаль милек объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү рөхсәт ителә.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 17.1 өлешен өстәргә:

«17.1. Шәһәр бюджеты үтәлеше барышында муниципаль милек объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү рөхсәт ителми, әлеге өлешнең икенче абзацында күрсәтелган очрактан тыш.

Шәһәр бюджеты үтәлеше барышында РФ Бюджет кодексының 78.2 маддәсендә каралган субсидияләрне алучылар булып торган бюджет яки автоном учреждениенең тибын яки муниципаль унитар предприятиенең оештыру-хокукый формасын билгеләнгән тәртиптә казна учреждениесенә үзгәрткән очракта, бюджет яки автоном учреждение, муниципаль унитар предприятие белән электән төзелгән килешүләргә килешү якларын алыштыру өлешендә (бюджет яки автоном учреждениене, муниципаль унитар предприятиене – казна учреждениесенә) һәм килешү төрендә (бюджет яки автоном учреждениенең, муниципаль унитар предприятиенең гражданлык-хокукый килешүен – муниципаль контрактка) үзгәреш кертеп, күрсәтелгән объектларга капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында карарга тиешле үзгәрешләр керткәннән соң, әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен бирү рөхсәт ителә.»;

6) 33 маддәнең 2 өлеше 1 пунктында «бюджет йөкләмәләрен кабул итү» сүзләрен «бюджет һәм акча йөкләмәләрен кабул итү һәм исәпкә алу» сүзләренә алыштырырга;

7) 38 маддәнең 4.1 өлешендә «бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм күрсәтлгән средстволар бюджетка күчерелгән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча тапшырылган бюджет чыгымнары турында элегрәк аңа бирелгән хисап нигезендә гамәлгә ашырыла» сүзләрен «бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм күрсәтлгән средстволар бюджетка күчерелгән көннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып күрсәтелгән бюджетара трансфертлар торган тиешле бюджет чыгымнары турында хисап нигезендә» сүзләренә алыштырыга;

8) 43 маддәнең 2 өлеше 2, 6 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга;

9) 45 маддәдә:

- 1 өлешнең 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

- 1 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләрнең, муниципаль

контрактларның шартларын үтәү, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, бюджет средстволарын мондый юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү өлешендә юридик затлар (муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре һәм устав капиталларында муниципаль берәмлек катнашкан җәмгыятьләрдән, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше булган коммерция оешмаларыннан тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар.»;

- 2 өлешнең икенче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Муниципаль финанс контроле контроль объектлары (бюджет процессында катнашучылар, бюджет һәм автоном учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре, устав капиталларында муниципаль берәмлек катнашкан җәмгыятьләрдән, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше булган коммерция оешмаларыннан тыш) мөнәсәбәтендә бюджеттан средстволар бирү турында килешүләрнең, муниципаль контрактларның шартларын, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, бюджет средстволарын мондый юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү өлешендә бюджет средстволарын төп бүлүчеләрне (бүлүчеләрне), бюджеттан средстволар бирүче бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларын тикшерү процессында гамәлгә ашырыла.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 2.1 өлешен өстәргә:

«2.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 265 маддәсе 2 пунктында күрсәтелгән органнар булмаган шәһәр бюджеты средстволарының баш администраторлары, Башкарма комитет органы (вазифаи затлары) булып торган муниципаль финанс контроле органы тарафыннан, бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруга анализ үткәрү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру максатында, соралган мәгълүматны һәм документларны тапшырырга бурычлы.»;

- 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Контрольдәге объектлар һәм аларның вазифаи затлары муниципаль финанс контроле органнарына аларның соравы буенча муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган мәгълүматны, документларны һәм материалларны вакытында һәм тулы күләмдә тапшырырга, муниципаль финанс контроле органнарының вазифаи затларына контрольдәге объектларның биналарында һәм территорияләрендә булырга рөхсәт бирергә, аларның законлы таләпләрен үтәргә бурычлы.

Контрольдәге объектлар тарафыннан әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны, документларны һәм материалларны муниципаль финанс контроле органнарына вакытсыз тапшыру яки тапшырмау, шулай ук тулы күләмдә тапшырмау яки ышанычсыз мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшыру,

муниципаль финанс контроле органнарының вазифаи затларының законлы эшчәнлегенә комачаулау Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән җаваплылыкка тарта.»;

8) 49 маддәдә:

- 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Эчке муниципаль финанс контроле органының гаризасы һәм күрсәтмәсе Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә төзелә һәм контроль объектларына җибәрелә.»;

- 2 өлештә:

«муниципаль финанс» сүзләре алдыннан «эчке» сүзен өстәргә;

«Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче башка норматив хокукый актларны бозу нәтиҗәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев